**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**города Азнакаево**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево,
423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592)
7-23-85
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай**
**муниципаль районы**
**Азнакай шәһәре**
**БАШЛЫГЫ**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай
шәһәре, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-
23-85
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«___27___» ____05____ 2025 ел. № ____108____

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Пушкин урамы буенча урнашкан шартлы рәвештә рөхсәт ителгән 16:44:010129:1270 кадастр номеры булган җир кишәрлегенә карар проекты буенча рөхсәт бирү хакында гавами тыңлауларны үткәрүне билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 39 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы “Азнакай шәһәре” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең рекреация билгеләнешендәге зонада (Р2) Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының карар проекты (кадастр номеры 16:44:0129:1270 булган җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты (Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы карар проекты) “Азнакай муниципаль районы” (Р2) зонада “Кибетләр”. рекреацион билгеләнештәге җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлауларны үткәрүне (алга таба - гавами тыңлаулар) билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны оештыручы итеп - Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитетын билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәрендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты турында фикер алышу буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Гавами тыңлауларны оештыручыга:

- җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гавами тыңлауларны оештыруны һәм уздыруны билгеләргә;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Пушкин урамы буенча урнашкан шартлы рәвештә рөхсәт ителгән 16:44:010129:1270 кадастр номерлы җир кишәрлеге белән уртак чикләре булган шушы җир кишәрлекләрендә урнашкан җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренә карар проекты буенча гавами тыңлауларны үткәрү турында хәбәрләр җибәргә.

5. Гавами тыңлаулар үткәрү чорын - кызыксынучы затларга аларны үткәрү турында хәбәр иткән вакыттан алып гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр билгеләргә. Гавами тыңлауларны уздыру срогы бер айдан артмаска тиеш.

6. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлегенә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясы нигезендә иҗтимагый фикер алышулар башлану турында хәбәрнамә әзерләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча»: http://aznakaevo.tatar.ru һәм шулай ук «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык М.З. Шәйдуллин

Азнакай муниципаль районы Башлыгы карарына кушымта
« ____»________ 2025 №_____

Шартлы рәвештә рөхсәт ителгән җир кишәрлеге карар проекты буенча
рөхсәт бирү хакында гавами тынлауларны билгеләү турында эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| *Эшче төркем рәисе:* | |
| Габдрахманов Э.Ә. | Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе |
| *Эшче төркем секретаре:* | |
| Авзалова А.З. | Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитетының шәһәр хуҗалыгы бүлеге баш белгече (килешү буенча) |
| *Эшче төркем әгъзалары:* | |
| Миндубаева Л.Ф. | Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитеты җитәкче урынбасары |
| Хәкимова Г.А. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесе (килешү буенча) |
| Габитова З.С. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлек җитәкчесе (килешү буенча) |